СОВЕТ
БОЛЬШЕАЧАСЫРСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ОЛЫ АЧАСЫР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2026 елның 18 марты Олы Ачасыр авылы № 29

Олы Ачасыр авыл җирлеге Советы карарының үз көчен югалтуын тану турында

Муниципаль хокукый актлар системасын актуальләштерү максатларында Зеленодольск муниципаль районының Олы Ачасыр авыл җирлеге Советы **карар итте:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Олы Ачасыр авыл җирлеге Советының 2022 елның 14 сентябрендәге 98 номерлы «Зеленодольск муниципаль районы составындагы Олы Ачасыр авыл җирлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру һәм массакүләм мәгълүмат чаралары тарафыннан бастырып чыгару өчен «Олы Ачасыр авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар, муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүчеләр һәм аларның гаилә әгъзалары тарафыннан тапшырылган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләрне бирү тәртибен раслау турында» «Олы Ачасыр авыл җирлеге» карарын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Интернет челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре составындагы Зеленодольск муниципаль районы мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru), шулай ук мәгълүмат стендларында: Олы Ачасыр авылы, Үзәк урамы, 46 йорт (җирлек хакимияте бинасы), Олы Ачасыр авылы, Кооператив урамы, 26 йорт (авыл мәдәният йорты бинасы) урнаштырырга.

Олы Ачасыр авыл жирлеге
башлыгы, Совет рәисе И.М. Саттаров